# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«11» 12 2024 ел          Яр Чаллы ш.          № 5535

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Тамчыкай» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Тамчыкай» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Тамчыкай» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 20 октябрендәге 3520 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы                                        К.Р. Нәҗмиев

Муниципаль район Башкарма комитетының 2024 елның «11» 12 5535 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елның 1 октябреннән ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Тамчыкай» балалар бакчасы буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Логопоезд» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Күңелле логика» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Театр студиясе» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 4 | «Кызыклы инглиз теле» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Тамчыкай» балалар бакчасы мөдире _______________ А.Р. Шәйхразиева

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары _______________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Тамчыкай» балалар бакчасы тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Логопоезд»** - артикуляция гимнастикасы, пальчик гимнастикасы, сөйләм аппаратын үстерү өчен бер үк вакытта лексик темаларны үзләштереп, күнегүләр ярдәмендә сөйләм кагыйдәләрен бозуга юнәлдерелгән. Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 50 кв.м., балалар саны - 13. Атнага бер тапкыр.

2. **«Күңелле логика»** - мәктәпкәчә яшьтәге балаларда заманча педагогик технологияләрне кулланып, элементар логик фикерләүне үстерүгә юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 50 кв.м., балалар саны - 16. Атнага бер тапкыр.

3. **«Театр студиясе»** - «Театр студиясе» - балаларның театр сәнгате һәм мәдәният өлкәсендәге иҗади сәләтләрен үстерүгә, кешелекнең рухи һәм мәдәни тәҗрибәсен бирүгә, мәктәпкәчә яшьтәге балаларда иҗади шәхес тәрбияләүгә юнәлдерелгән. Программа «Театр-иҗат-балалар»да эшләнгән. Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 50 кв.м., балалар саны - 14. Атнага бер тапкыр.

4. **«Кызыклы инглиз теле»** - баланың шәхесен, аның сөйләм эшчәнлеген, шулай ук иҗади сәләтләрен һәрьяклап үстерүгә юнәлдерелгән. Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 50 кв.м., балалар саны - 16. Атнага бер тапкыр.

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет
мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе –
«Тамчыкай» балалар бакчасы мөдире _______________ А.Р. Шәйхразиева

ДЕТСКИЙ САД "ТАМЧЫКАЙ" ИНН 1639019198